КИЛЕШКӘН
Казан шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең
Вахитов һәм Идел буе
районының мәгариф бүлеге башлыгы

_____________ М.З.Закирова

РАСЛАНДЫ
Казан шәһәре Вахитов районының
"Балалар иҗат үзәге» өстәмә
белем муниципаль
бюджет учреждениясе директоры

_____________ Р.Р.Саляхова

## Н И Г Е З Л Ә М Ә

Район буенча үткәреләчәк "Казан сандугачы-2017" җыр бәйгесе тәртибе.

**Район оештыру әгъзалары**:
Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең Вахитов һәм Идел буе районнары мәгариф бүлеге һәм Казан шәһәре Вахитов районының Балалар иҗат үзәге

**Бәйгенең максатлары һәм бурычлары:**
- татар эстрада җырларын иң оста башкаручыларны сайлап алу;
- балаларда татар халык сәнгатенә, мәдәниятенә, көй-моңнарына мәхәббәт уяту;
- балалар репертуарларында фольклор-этнографик композицияләре булдыру;
- сәләтле балалар табу;
- яшь талантларны үстерү.

**Үткәрү тәртибе:**
Бәйге Казан шәһәре Вахитов районының балалар иҗаты узәге, Сул Болак урамы, 48/1 адресы буенча **Идел буе районы** өчен – **2017 елның 16 гыйнварында** ,
**Вахитов районы** өчен **– 2017 елның 17 гыйнварында** түбәндәге сәгатьләрдә үткәрелә:
13:00 - кече төркем - 6-9 яшь;
14:00 - урта төркем – 10-13 яшь;
15:30- олы төркем – 14-18 яшь.
һәр номинациядә җинүче 2017 елның 31 гыйнварында шәһәр этабында үткәреләчәк «Казан сандугачы» бәйгесендә, шулай ук «Казан-йорт» фестивалендә йомгаклау концертында катнаша.

**Җыр бәйгесе өч номинациядә үткәрелә:**
- татар эстрада җыры;
- татар халык җыры;
- фольклор композициясе;
Катнашучылар 1 номер башкара.
Бәйгедә 6 яшьтән 18 яшькә кадәр теләкләре булган балалар катнаша ала. Алар, яшь аермасына карап, 3 төркемгә бүленә:
6-9 яшькә кадәр; 10-13 яшькә кадәр; 14-18 яшькә кадәр.

**Катнашучылар:**

Бәйгедә Вахитов һәм Идел буе районнары урта мәктәп һәм балалар иҗат үзәкләрендә шөгыльләнүче укучылар катнаша ала. Гаризалар Казан шәһәре Вахитов районының Балалар иҗаты узәгенә кабул ителә.

**Бәйгенең таләпләре:**

- чиста, әйбәт дикция белән башкару;
- артистлык осталыгы ( сәхнәдә үзеңне иркен, культуралы тота белү, йөз мимикасы, тән хәрәкәте, композициянең эчтәлегенә туры килү );
- микрофонны куллана белү;
- сәхнә киеме культурасы.

**Бәйгегә нәтиҗә ясау:**

Йомгаклау гыйнвар аенда, шунда ук бүләкләү.
Оештыру һәм җюри әгъзалары:
жюрида югары квалификацияле педагоглар һәм җөмһүриятебезнең танылган сәнгать осталары булачак.
Призлы урыннар алган укучылар номинация буенча бүләкләнә.
Гаризалар 30 нчы декабрьгә кадәр түбәндәге адреска кабул ителә,
e-mail: valiullina.lyalya@mail.ru
Шәһәр этабында районда I, II , III урыннар алган балалар катнаша.
Белешмәләр өчен телефоннар: 292-22-68
Кәрәзле телефон: 89172220848 (Валиуллина Ляля Заетовна –бәйгенең кураторы)